**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

27.08.2018 209

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының аерым боерыкларын көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Экология һәм Табигый ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Җир ресурсларына һәм үсемлекчелеккә китерелгән зыянны түләттерү күләмен билгеләү тәртибе»н гамәлгә кертү турында» 2002 елның 08 апрелендәге 314 номерлы;

«Җир ресурсларына һәм үсемлекчелеккә китерелгән зыянны түләттерү күләмен билгеләү тәртибе»н гамәлгә кертү турында» 2002 елның 08 апрелендәге 314 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 08 августындагы 846 номерлы;

«Җир ресурсларына һәм үсемлекчелеккә китерелгән зыянны түләттерү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 28 октябрендәге 1204 номерлы;

«Җир ресурсларына һәм үсемлекчелеккә китерелгән зыянны түләттерү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 13 апрелендәге 259 номерлы.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Документларны тикшерүдә тоту бүлегенә (Г.Р.Хәннанова) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы үзәк аппаратының структур бүлекчәләре һәм территориаль идарәләре башлыклары игътибарына җиткерергә.

4. Документларны тикшерүдә тоту бүлегенә (Г.Р.Хәннанова) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы үзәк аппаратының структур бүлекчәләренә һәм территориаль идарәләренә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Әйләнә-тирә мохитне саклау объекты буларак туфракка китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2010 елның 8 июлендәге 238 номерлы боерыгына таянып эш итәргә.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков